ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӨРЕШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БӨРЕШЛЕ АВЫЛЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР
2019 елның 30 ноябреннән № 1

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлегенең
Бөрешле авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә, I һәм II төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан тыш.

2. Үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- агачларны кисү;
- генератор сатып алу;
- хәбәр итү системалары өчен җиһазлар сатып алу.

3. Бөрешле авылының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Бөрешле авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бөрешле авыл җирлеге башлыгы Л.А. Смирнова